**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7392**
**22.12.2022**

Җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су
белән тәэмин итүнең) ачык системаларыннан файдаланып
кайнар су белән тәэмин итүне туктату турында

Яр Чаллы шәһәре кулланучыларын үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итүнең ачык системасын Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2019 елның 8 ноябрендәге 1194 номерлы приказы белән расланган 2020 елга Яр Чаллы шәһәрен җылылык белән тәэмин итү схемасы белән каралган, автомат индивидуаль җылылык пунктларыннан файдаланып, үзәкләштерелмәгән кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасына күчерү буенча чаралар үтәлү тәмамлану белән бәйле, «Су белән тәэмин итү һәм кулланылган суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 8 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясындагы 9 өлеше нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре кулланучыларын үзәкләштерелгән җылылык белән тәэмин итүнең ачык системасын, автомат индивидуаль җылылык пунктларыннан файдаланып, үзәкләштерелмәгән кайнар су белән тәэмин итүнең ябык системасына күчерү буенча чараларны үтәлгән дип танырга.
2. 2023 елның 1 гыйнварыннан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә җылылык белән тәэмин итүнең (кайнар су белән тәэмин итүнең) ачык системасыннан файдаланып, кайнар су белән тәэмин итүне туктатырга.
3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш.Салахов